

Гадәт буенча, һәр елны Зубово-Поляна районы татар авылларында (Тат.- Лундан, Кочетовка, бәйрәмгә Горенка авылыннан да киләләр) “Кыр кырбаны” vткәрәләр. Бу ата-бабаларыбыздан сакланып калган бәйрәм; кайсы авылда vткәрсәләр дә, барлык авыл халкы очен уртак.
“Кыр корбаны” бәйрәме дога кылу белән башлана, ә аннара Аллаһы Тәгаләдән уныш мул булып vсvне, доньяларда тынычлык булуны, тәбигатьнен рәхимле булуын сорап, корбан бугазлана. Гадәт буенча, бу конне халык хужалыкларында бернинди эш эшләми.

Ә Бәйрәм алдыннан авыл аксакаллары белән әбиләре, оч кон беррәттән, авыл яны кырына



теләкләр теләv намазларын укырга чыгалар. Оченче кон, намаздан сон, корбанны Вахит хәзрәт Немешев укып бугазлый. Иттән, урнашылганы гадәт буенча, халыкны сыйлау максаты белән, яна эшкәртелгән иткә салма пешерәләр.
Әзер салынган салманы авыл хатын-кызлары ойләреннән алып киләләр. Быел да зур-зур казаннарда, Динар Утемишев белән Анвар Канчеров, тырыша-тырыша, хормәтле

авылдашлары һәм кунаклар очен, тәмле аш пешергәннәр.



Кунаклар дигәндә, алар арасында безгә таныш Казан галимнәре. Аларны бу районда Зубово-Поляна районы башлыгы урынбасары Ю.В.Чекмарев белән Горенкада авылжирлеге башлыгы вазифаларын башкаручы Е.Д.Филиппова каршы алган. Аннары бергәләп Татар Лунданында милли татар йоласы буенча vткәрелә торган “Кыр корбаны”нда катнашканнар.



Бәйрәмгә, Татар Лунданы белән Кочетовка авыл халкы, алдан киселеп куйган салма белән казыдан башка, милли камыр ризыклары –пәрәмәчләре белән бергә, алып киләләр. Зур-зур эскәтерләр җәеп хуш исле самовырда кайнатылган чәйле остәлләр артына утырып бәйрәм иткәннәр. Мордовия халкы бик тә кунакчыл. Халык чәчәкле-vләнле кырда рәхәтләнеп сыйлансалар, авылдагы бер кешене да онытмыйча, гадәт буенча, “Кыр корбаны” бәйрәменә килә алмаган картларга, аш-суны ойләренә илтеп бирәләр. Этнографлар мондый йола турында ишеткәннәре булган, әмма беренче тапкыр катнашканнары турында әйткәннәр. Аннары галимнәр авылнын олкән яшьтәге кешелә



[illegible]